**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

_13.09.2022_ _ 802-п _

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән аны геологик өйрәнү өчен файдалану хокукы бирүгә гаризаларны карау тәртибен раслау турында» 2020 елның 6 июнендәге 645-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән аны геологик өйрәнү өчен файдалану хокукы бирүгә гаризаларны карау тәртибен раслау турында» 2020 елның 6 июнендәге 645-п номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 28 апрелендәге 469-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә боерык бирәм:»;

әлеге боерык белән расланган Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү өчен гаризаларны карау тәртибендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы) $10^1$ статьясының 7 пунктындагы 5 абзацын, «Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы «г» пунктын гамәлгә ашырганда гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында карарлар кабул иткәндә монополиягә каршы таләпләрне үтәү максатларында эшләнде.»;

2.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү максатларында эзләү һәм бәяләү максатларында, геологик өйрәнү максатларында исемлеккә кертелгән җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алу өчен, мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү өчен, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен һәм берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү өчен җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында аларны геологик өйрәнү, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен һәм җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында аларны геологик өйрәнү һәм аларны чыгару өчен, коммерциясез бакчачылык ширкәтләрендә һәм (яки) коммерциясез яшелчәчелек ширкәтләрендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә яки техник су белән тәэмин итү максатлары өчен кулланыла торган җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмаларны чыгаруга бәйле булмаган максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирү тәртибен раслау турында» 2022 елның 15 июнендәге 564 номерлы карары белән расланган форма буенча гариза әзерли һәм Министрлыкка җибәрә, аңа түбәндәгеләр теркәлә:

гариза бирүченең гамәлгә кую документларының күчермәләре (әгәр гариза бирүче булып юридик зат торса);

гариза бирүченең соңгы хисап датасына бухгалтерлык балансы күчермәсе, аны кабул итү турында салым органы тамгасы белән;

гариза бирү датасына кадәр бер ай эчендә гариза бирүче счетлары буенча акчалар әйләнеше турында банк оешмаларыннан белешмәләр;

кредит яки кредит килешүләре күчермәләре (булган очракта);

подряд килешүләренең күчермәләре (булган очракта);

кулланыла торган технологияләр турында белешмә, аларны тасвирлап, бораулау һәм тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чаралар исемлеге, аларның гариза бирүчегә яисә җәлеп ителә торган подрядчыга каравын дәлилләп;

гариза бирүченең яки җәлеп ителә торган подрядчыларның штат расписаниесе күчермәсе;

эшләрне башкарачак белгечләрнең квалификация дипломнары күчермәләре;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләү турындагы документ реквизитлары;

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик план күчермәсе (өч нөсхәдә);

файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең гариза бирү мизгеленә торышын чагылдыра торган һәм эшләрне башлауда планлаштырыла торган сроклар һәм җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турындагы белешмәләрне үз эченә алган аңлатма язуы.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланырга яки оригиналлар күрсәтеп тапшырылырга тиеш.»;

2.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Министрлык тиешле дәүләт органнарыннан түбәндәге документларны мөстәкыйль рәвештә соратып ала:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан) өземтә;

гариза бирүченең салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп;

салым һәм җыемнар түләү буенча бурычлар булуы яки булмавы турында салым органнарыннан белешмә;

гариза бирүченең һәм җир асты байлыклары участокларыннан файдалануга бәйле эшчәнлек төрләренә җәлеп ителә торган подрядчыларларның лицензияләре күчермәләре (булган очракт).»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 14 статьясы нигезендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турындагы гаризаны кабул итүдә түбәндәге очракларда баш тарта:

лицензия алуга гариза билгеләнгән таләпләрне бозып бирелгән очракта;

гариза бирүче аңлы рәвештә үзе турында дөрес булмаган белешмәләр тапшырганда;

мөрәҗәгать итүче җир асты байлыкларыннан файдалануны нәтиҗәле һәм куркынычсыз уздыру өчен кирәкле финанс һәм техник чараларга, квалификацияле белгечләргә ия булуы яки ия булачагы турында дәлилләмәләр тапшырмаган очракта һәм тапшыра алмаса;

әлеге мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгән очракта монополиягә каршы таләпләр үтәлмәсә;

«Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының $14^1$ статьясының икенче өлешендә каралган шарт булуы.».

2. Хокукый тәэмин итү бүлеге әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

Министр А.В. Шадриков